| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 6 декабрь № 896

г. Казань

Казан шәһәренең «2 нче балалар стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен ябу турында

Казан шәһәрендә дәүләт медицина оешмалары челтәрен оптимальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәренең «2 нче балалар стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен (алга таба – «2 нче балалар стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 420103, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Ямашев урамы, 52 нче йорт адресы буенча урнашкан «2 нче балалар стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен ябу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен, өч көн эчендә теркәү органына «2 нче балалар стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең ябылу процессында торуы турында мәгълүматлар тапшырырга;

14 көн эчендә:

«2 нче балалар стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең ликвидация комиссиясе составын расларга;

Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә «2 нче балалар стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен ябу тәртибен һәм вакытларын билгеләргә;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә «2 нче балалар стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен ябу нәтиҗәсендә эштән чыгарыла торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә, шулай ук норматив хокукый актларда каралган башка ликвидация чараларын гамәлгә ашырырга;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына «2 нче балалар стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә беркетелгән дәүләт мөлкәтеннән алга таба файдалану турында тәкъдимнәр кертергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\896.doc